МИНИСТЕРСТВО СЕЛЬСКОГО ХОЗЯЙСТВА И ПРОДОВОЛЬСТВИЯ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫ ҺӘМ АЗЫК-ТӨЛЕК МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

16.08.2017 г.Казань № 186/2-пр

“Иң яхшы комбайнчы” республика конкурсын уздыру турында нигезләмәне раслау хакында

Комбайнчы һөнәренең абруен арттыру һәм аны популярлаштыру, Татарстан Республикасы агросәнәгать паркына караганурып-җыю техникасы паркын нәтиҗәле файдалану һәм 2017 елда урып-җыю кампаниясе барышында югары күрсәткечләргә ирешкән комбайнчыларны бүләкләү максатларында

боерык бирәм:

1. “Иң яхшы комбайнчы” республика конкурсын уздыру турында нигезләмәне расларга.

2. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшерен торуны министрның беренче урынбасары Н.Л. Титовка йокләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры урынбасары –
министр М.Г. Әхмәтов

Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының 2017 елның 16 августындагы 186/2-пр номерлы боерыгы белән расланды

# “Иң яхшы комбайнчы” республика конкурсын уздыру турында нигезләмә

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Нигезләмә 2017 елда “Иң яхшы комбайнчы” республика конкурсын оештыруның һәм уздыруның максатын, тәртибен билгели (алга таба – Нигезләмә).

1.2. 2017 елда “Иң яхшы комбайнчы” республика конкурсын (алга таба – конкурс) уздыруның максаты Татарстан Республикасы территориясендә 2017 елгы урып-җыю кампаниясе барышында сугып алынган иген күләме һәм чабылган печән мәйданы буенча югары күрсәткечләр биргән иң актив комбайнчыларны бүләкләүдән гыйбарәт.

1.3. Конкурсны оештыручы – Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы (алга таба – Министрлык).

1.4. Конкурсны уздыру сроклары, шартлары һәм нәтиҗәләре турында мәгълүмат “Татарстан Республикасы Рәсми порталы” Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы составында Министрлыкның рәсми сайтына урнаштырыла.

1.5. Конкурсны оештыруга һәм уздыруга бәйле чыгымнарны финанслауны Министрлык гамәлгә ашыра.

1.6. Конкурсны оештыру һәм уздыру эше түбәндәге принципларга нигезләнә:

гавамилык һәм ачыклык;

конкурста катнашучыларның тигезлеге.

## 2. Конкурста катнашучылар

2.1. Конкурста катнашуга икмәк җыю комбайннарында, үзйөрешле печәнчапкычларда һәм иген ургычларда эшләүче барлык механизаторлар да кертелә.

## 3. Конкурс комиссиясе һәм аның эшләү тәртибе

3.1. Конкурс җиңүчеләрен билгеләү өчен конкурс комиссиясе (алга таба – комиссия) оештырыла. Комиссия составы Министрлык боерыгы белән

раслана. Комиссия составына кертелгән вазыйфаи затларның персональ составында үзгәрешләр булса, аңа Министрлык боерыгы белән тиешле үзгәрешләр кертелә.

3.2. Комиссия эше утырышлар рәвешендә аның әгъзаларының кимендә яртысы булганда башкарыла.

3.3. Комиссия составына комиссиянең рәисе, рәистәше, секретаре һәм әгъзалары керә.

3.4. Комиссия рәисе:

комиссия эшен оештыра;

комиссия утырышларын уздыру урынын, вакытын билгели;

комиссия утырышының көн тәртибен раслый;

комиссия әгъзаларына йокләмәләр бирә.

3.5. Комиссия утырышларын комиссия рәисе яки аның йөкләмәсе буенча рәистәше (алга таба – рәислек итүче) үткәрә.

3.6. Комиссиясекретаре:

комиссия утырышының көн тәртибен һәм материалларын әзерли;

комиссия утырышының көн тәртибен раслау очен комиссия рәисенә тәкъдим итә;

комиссия утырышлары беркетмәләрен әзерләүне башкара.

3.7. Комиссия әгъзалары аның утырышларында шәхсән үзләре катнаша.

3.8. Комиссия карары ачык тавыш бирү юлы белән утырышта катнашучы комиссия әгъзалары биргән тавышларның гади күпчелегенә нигезләнеп кабул ителә. Тавышлар тигез булганда, рәис тавыш биргән карар кабул ителгән дип санала.

3.9. Комиссия карары утырыш беркетмәсе белән рәсмиләштерелә, ул конкурс уздыру датасыннан алып оч эш көне эчендә рәислек итүче һәм комиссия секретаре тарафыннан имзалана.

3.10. Комиссия түбәндәгеләргә хокуклы:

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, агросәнәгать комплексы оешмаларыннан һәм аларның вазыйфаи затларыннан комиссия эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен кирәкле мәгълүмат соратып алырга;

комиссия компетенциясенә кертелгән мәсьәләләр буенча фикер алышу очен үз утырышларына Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, агросәнәгать комплексы оешмалары җитәкчеләрен, вазыйфаи затларын һәм башка вәкилләрен, шулай ук башка затларны чакырырга;

тапшырылган мәгълүматның дөреслеген тикшерергә;

законнар нигезендә башка вәкаләтләрне гамәлгә ашырырга.

3.11. Комиссия, әлеге Нигезләмә белән билгеләнгән конкурсны оештыру һәм уздыру тәртибенә нигезләнеп, конкурста катнашучыларның эшчәнлеген бәяли, конкурсның җиңүчеләрен һәм бүләкләнүчеләрен билгели һәм алар арасында премияне түбәндәге санда һәм күләмдә бүлә:

конкурсның бер җиңүчесенә 100 мең сум күләмендә (НДФЛны тотып калып) бер премия.

Конкурс җиңүчеләре барлыгы 200.

4. Конкурсны оештыру һәм уздыру тәртибе

4.1. Конкурс уздыру датасы турында карар комиссия тарафыннан кабул ителә. Конкурс уздыру турында белдерү “Татарстан Республикасы Рәсми порталы” Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы составында Министрлыкның рәсми сайтына урнаштырыла.

4.2. Конкурс уздырганда конкурста катнашучының эшчәнлеге түбәндәге күрсәткечләр буенча бәяләнә:

иген җыю комбайны–сугып алынган бөртекле һәм бортекле-кузаклы культураларның иң күп күләме буенча;

үз йөрешле печән чапкычлар һәм иген ургычлар – урып-сугылган мәйданнарның иң югары зурлыгы буенча.

Иген җыю комбайннары торкемендә җиңүчеләр дип Татарстан Республикасында сугып алынган бөртекле һәм бөртекле-кузаклы культураларның иң күп күләме буенча иң яхшы нәтиҗәләр күрсәткән катнашучылар таныла.

Үз йөрешле печән чапкычлар һәм иген ургычлартөркемендә җиңүчеләр дип Татарстан Республикасында урып-сугылган мәйданнарның иң югары зурлыгы буенча иң яхшы нәтиҗәләр күрсәткән катнашучылар таныла.

Иген җыю комбайннарын,үз йөрешле печән чапкычларны һәм иген ургычларны җитештерүчәнлек буенча төркемләү Нигезләмәгә кушымтада билгеләнә.

4.3. Конкурс нәтиҗәләре конкурс комиссиясе утырышы беркетмәсе имзаланган көннән алып өч эш көне эчендә “Татарстан Республикасы Рәсми порталы” Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы составында Министрлыкның рәсми сайтына урнаштырыла.

4.4. Премияләрне тапшыру Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

"Иң яхшы комбайнчы" республика конкурсын уздыру турында нигезләмәгә кушымта

Иген җыю комбайннарын,
үз йөрешле печән чапкычларны һәм иген ургычларны
төркемләү

**Иген җыю комбайннары буенча**

| Комбайн классы | Комбайннар маркасы |
|---|---|
| 1 | СК-5 "Нива"<br>"Вектор-410/420",<br>"КЗС-7", "Енисей" |
| 2 | ДОН-1500/1200,<br>Акрос-530/550,<br>КЗР-10 "Полесье",<br>КЗС-812, КЗС-10К,<br>Кейс-2366,<br>КлаасДоминатор МЕГА-204/208,<br>"Нью Холланд" ТС-56, ТХ-65 |
| 3 | Акрос-580/585/595,<br>КЗС-1218,<br>Нью ХолландCSX, CX, CS,<br>Клаас Мега-360/370,<br>КлаасТукано 430-450/470-480,<br>КлаасЛексион-480/540,<br>Джон Дир 9560/9660/9670,<br>Джон ДирW540 |
| 4 | КлаасТукано570/580,<br>Торум-740/750,<br>КлаасЛексион-560/570/580/650/670/740/770 |

**Үз йөрешле печән чапкычлар буенча**

| Комбайн классы | Печән чапкычлар маркасы |
|---|---|
| 1 | МакДон, Челленджер, ДжонДир, ЕС-1 |
| 2 | Е-302, КПС-5, "Мещера" |
| 3 | ЖРБ-4,2, ЖВН-6 |